| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Азевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Азево авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2024 Азево авылы № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Азево авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Азево авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Азево авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Азево торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын 2024 елның 28 октябрь көнне 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы “Азево авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Азево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), студентлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ирекле рәвештә киткәннәрдән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (аларның ата-аналарын, хатыннары, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итеп һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдереп, гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга: 2025 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертү һәм куллану белән килешәсезме?”:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү,ремонтлау, карап тоту (Совет, Заречная урамнары буенча юлларны вак таш белән сатып алу һәм салу һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

- торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән һәм чүп үләннәрен чаптыру, юлларны кардан чистарту, тракторны тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәт килешүе буенча түләү)

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү *(янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар)*

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Адресы: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Азево авылы, Совет ур., 22 а йорты, авыл клубы территориясе.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Интерне» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык В.С.СЕМЕНОВ